БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 04 2021 ел № 162

«Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 5 июлендәге 254 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Төзелеш өлкәсендә бердәм заказчы» гавами–хокукый компания турында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 декабрендәге 435 номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2009 елның 5 июлендәге 254 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (19 нчы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. 1 нче кушымтадагы Россия Федерациясе Җир кодексыннан Өземтәнең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«39) «Төзелеш өлкәсендә бердәм заказчы» гавами–хокукый компания турында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә агымдагы елга һәм план чорына «Төзелеш өлкәсендә бердәм заказчы» гавами–хокукый компания эшчәнлеге программасына кертелгән инженер тикшеренүләрен башкаруны тәэмин итү, архитектура-төзелеш проектлауны, капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны, сүтүне тәэмин итү өчен җир кишәрлеге».

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2009 елның 5 июлендәге 254 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак затларны исәпкә кую (Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы

нигезендә) һәм гражданнарга өлешле милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентка (16 нчы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.5 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе»;

2.2. 2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов